Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №LII-2**

13 март 2020 ел

Балык Бистәсе штп.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне нәтиҗәле гамәлгә ашыру максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы, 1992 елның 21 февралендәге "Җир асты байлыклары турында" 2395-1 номерлы, 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, шулай ук 2017 елның 24 июлендә төзелгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына тапшыру турындагы Килешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты

корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирергә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына:

3.1) әлеге карарны гамәлгә ашыру максатларында муниципаль хокукый актлар кабул итәргә;

3.2) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә хезмәттәшлекне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы вазифаларын башкаручы Ф.Г.Әхмәтҗанова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2020 елның
13 мартындагы LII-2 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы, 1992 елның 21 февралендәге "Җир асты байлыклары турында" 2395-1 номерлы, 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ номерлы Федераль законнар (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон), Татарстан Республикасының 1992 елның 25 декабрендәге "Җир асты байлыклары турында" 1722-XII номерлы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, шулай ук башка муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде.

2. Нигезләмә оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, шулай ук физик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы (алга таба – район) территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

3. Кайсы ведомствога каравына һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан барлык җир асты байлыклары, шул исәптән федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы милкендәге җирләр муниципаль контроль объекты булып тора.

4. Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты

байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне (алга таба - муниципаль контроль) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба - муниципаль контроль органы, районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы) гамәлгә ашыра.

5. Район территориясендә муниципаль контроль мәсьәләләрен алып баручы районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе һәм рәис урынбасары – районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы бүлеге башлыгы җир мөнәсәбәтләре объектларыннан файдалану буенча муниципаль инспекторлар (алга таба – муниципаль инспекторлар) булып тора.

6. Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук гражданнар белән үзара элемтәдә эш итәләр.

## 2. Муниципаль контрольнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Муниципаль контрольнең максатлары булып җир законнарын бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җир асты байлыкларын рациональ, нәтиҗәле файдалануга һәм шартнамәдәге йөкләмәләрнең үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру тора.

2.2. Муниципаль контрольнең төп бурычлары булып җир законнарын үтәү, юридик, вазифаи һәм физик затлар тарафыннан билгеләнгән таләпләрне (нормаларны, кагыйдәләрне, нормативларны) үтәү тора.

2.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы түбәндәгеләргә контрольлек итүне гамәлгә ашыра:

1) аренда шартнамәләрен үз вакытында төзү һәм җир кишәрлекләренә хокукларны дәүләт теркәвенә алу;

2) җир асты байлыкларыннан максатчан һәм рөхсәт ителгән файдалану төре буенча файдалану;

3) җиргә хокукны таныклаучы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлардан башка аларны үз белдеге белән файдалануны юкка чыгара торган тәртипне үтәү;

4) җирләрне вакытында кайтару;

5) җирләрнең торышы турында дөрес мәгълүматлар бирү;

6) аренда түләвен вакытында һәм дөрес түләү;

7) җир кишәрлекләрендә закон нигезендә билгеләнгән ызанлау, геодезия һәм башка махсус билгеләр булу һәм аларның сакланышы;

8) җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә бозуларны бетерү һәм җир законнарын үтәү турындагы таләпләрнең үтәлеше;

9) җирләрдән файдалану мәсьәләләре буенча үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә башка функцияләр.

## 3. Планлы тикшерүләрне оештыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Планлы тикшерүне уздыру предметы булып юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм физик затлар тарафыннан җир законнары нормаларын һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү тора.

3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

3.3. Планлы тикшерүләр муниципаль контроль органы тарафыннан аның вәкаләтләре нигезендә эшләнә һәм раслана торган еллык планнарга ярашлы рәвештә уздырылалар.

3.4. Планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) атамалары, план буенча тикшерелергә тиешле индивидуаль эшкуарларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыннары яки индивидуаль эшкуарлар тарафыннан эшчәнлекләрен фактта гамәлгә ашыру урыннары;

2) һәр планлы тикшерүне үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерүнең башлану датасы һәм үткәрелү срогы;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыручы муниципаль контроль органының атамасы. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан планлы тикшерү уздырганда мондый тикшерүдә катнашучы барлык органнарның исемнәре бергә күрсәтелә.

3.5. Планлы тикшерүләрне үткәрүнең расланган еллык планы кызыксынучы затларга аны муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән җиткерелә.

3.6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагысының 1 сентябренә кадәр билгеләнгән тәртиптә, 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ

номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, прокуратурага планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык план проектын җибәрә.

3.7. Планлы тикшерүләрне уздыруның еллык планына планлы тикшерүне кертү өчен нигезләр 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән.

3.8. Планлы тикшерүне үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга муниципаль контрольне үткәрү башланганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча тикшерүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан планлы тикшерүне уздыруны башлау турында муниципаль контроль органы күрсәтмәсенең күчермәсен тапшыру турындагы хәбәрнамә белән заказлы почта җибәрүе аша һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар әйләнеше ярдәмендә һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның электрон почта адресына юлланган яисә башка мөмкин булган ысул белән хәбәр ителә.

3.9. Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата планлы күчмә тикшерү үткәрү срогы кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен елына унбиш сәгатьтән артык була алмый.

3.10. Күчмә планлы тикшерү уздыручы урындагы затларның дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләр, махсус экспертиза һәм тикшерүләр уздыру зарурлыгына бәйле аерым очракларда күчмә планлы тикшерүне уздыру вакыты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма егерме эш көненнән дә артыкка түгел кече предприятиеләргә карата, микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән дә артыкка түгел.

## 4. Планнан тыш тикшерүләрне оештыру һәм уздыру тәртибе

4.1 Планнан тыш тикшерү 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсенең 2 өлеше нигезендә уздырыла, аңа ярашлы рәвештә планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) мәҗбүри таләпләрне һәм (яисә) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне ачыкланган бозуны бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәне дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан үтәү срогы тәмамлану;

2) юридик затка, индивидуаль эшкуарга карата планнан тыш тикшерү үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәтнамә (лицензия) бирү, рөхсәтнамә бирү (килештерү) кагыйдәләре белән каралган булса, муниципаль контроль органына юридик затның яисә индивидуаль эшкуарның аңа хокукый статус, эшчәнлекнең аерым төрләрен

гамәлгә ашыру яисә башка юридик әһәмиятле гамәлләрне башкаруга рөхсәт бирү хокукына махсус рөхсәтнамә (лицензия) бирү турында гаризасы керү,

3) дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлексез контрольдә тоту чараларының нәтиҗәләрен анализлау, муниципаль контроль органнарына кергән гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшкуарлар, юридик затларның мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, гаммәви мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматны карау яисә алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль контроль органы вазифаи затының түбәндәге фактлар турында дәлилле тәкъдиме:

а) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Милли китапханә фонды составына керә торган аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга зыян китерү куркынычы, дәүләт иминлегенә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Милли китапханә фонды составына керә торган аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә һәм прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе нигезендә чыгарылган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы җитәкчесе боерыгы (күрсәтмәсе).

4.2. Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

4.3. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә планнан тыш күчмә тикшерү дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан әлеге матдәнең 4.1 өлешендәге 3 пунктының "а", "б" пунктчаларында күрсәтелгән нигезләрдә мондый юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештерелгәннән соң үткәрелергә мөмкин.

4.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе күрсәтмәсенә кул куйган көндә, аны үткәрүне

килештерү максатларында, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында муниципаль контроль органы заказлы почта җибәрүен тапшыру турындагы хәбәрнамә белән яисә электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү хакында гариза тапшыра яисә җибәрә.

Бу гаризага Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Рәисенең планнан тыш урынга чыгып (күчмә) тикшерү уздыру турындагы күрсәтмәсенең күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган документлар теркәлә.

4.5. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында, әлеге маддәнең 4.1 өлешендәге 3 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән гайре, юридик затка, индивидуаль эшкуарга дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы тарафыннан аны үткәрү башланганчы кимендә егерме дүрт сәгать кала теләсә нинди мөмкин булган ысул белән хәбәр ителә, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса яки элек юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына тапшырылган булса.

## 5. Тикшерүне оештыру тәртибе

5.1. Тикшерү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе күрсәтмәсе (боерыгы) нигезендә үткәрелә. Тикшерү бары тик боерыкта күрсәтелгән вазифаи зат яисә вазифаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

5.2. Боерык Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының тикшерү үткәрүче вазифаи заты тарафыннан җитәкчегә, урындагы башка затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка бер үк вакытта хезмәт таныклыкларын күрсәтеп кул куйдырып тапшырыла. Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча тикшерүне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар үз вәкаләтләрен раслаучы мәгълүмат бирергә тиешләр.

5.3. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр документлар тикшерү рәвешендә һәм (яки) 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ номерлы Федераль законның 1,12 маддәләрендә каралган тәртиптә күчмә (урынга барып) тикшерү рәвешендә үткәрелә.

## 6. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

6.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының вазифаи заты тарафыннан ике нөсхәдә акт төзелә (тикшерү актының үрнәк рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә).

6.2. Тикшерү актына мәйданнарны үлчәү схемалары, фототаблицалар, кирәк булган очракта, җир кишәрлеген тикшерү акты, үткәрелгән экспертизалар бәяләмәләре, мәҗбүри таләпләрне яисә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән юридик зат хезмәткәрләре, индивидуаль эшкуарлар һәм физик затлар аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яисә аларның күчермәләре теркәлә.

6.3. Тикшерү акты ул тәмамлаганнан соң ук ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, шуларның берсе кушымталарның күчермәләре белән бергә, җитәкчегә, башка вазифаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка танышу турында яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында кул куйдырып тапшырыла. Җитәкче, урындагы башка зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, физик зат булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат танышу турында раслама бирүдән яки тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында раслама бирүне кире каккан очракта. Акт тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта җибәрүе аша юллана, ул делода саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

6.4. Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән үлчәүләр, тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль эшләре тәмамланганнан соң өч эш көненнән артмаган срокта төзелә һәм ул җитәкчегә, башка вазифаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка раслама алып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта җибәрүе аша юллана, ул муниципаль контроль органы делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

6.5. Планнан тыш күчмә (урынга чыгып) тикшерү үткәрү өчен аны прокуратура органы белән килештерү таләп ителсә, тикшерү актының күчермәсе тикшерү акты төзелгән көннән алып биш эш көне эчендә тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына җибәрелә.

## 7. Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозу фактларына карата муниципаль контроль органының урындагы затлары тарафыннан күрелә торган чаралар

7.1. Тикшерү барышында юридик зат, индивидуаль эшкуар яки физик зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне яисә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән

таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү үткәргән урындагы затлар үз вәкаләтләре чикләрендә бурычлы:

1) ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча административ чаралар күрү өчен тикшерү материалларын дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына җибәрергә;

2) ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне контрольдә тоту буенча чаралар күрергә.

## 8. Муниципаль контроль чаралары үткәргәндә җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир кишәрлекләрен арендалаучыларның хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы

8.1. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир кишәрлекләрен арендалаучылар яки аларның законлы вәкилләре муниципаль контроль буенча чаралар үткәргәндә хокуклы:

1) тикшерү вакытында турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) тикшерү предметына караган һәм әлеге административ регламентта һәм башка норматив хокукый актлар тарафыннан бирү күздә тотылган мәгълүматны алырга;

2.1) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелек) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан алар карамагындагы документлар һәм (яисә) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яки дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән танышырга;

2.2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратыла торган документларны һәм (яисә) мәгълүматны үз инициативасы белән дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына тапшырырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы турында, алар белән килешү яки алар белән, шулай ук муниципаль контроль органы вазифаи затларының аерым гамәлләре белән килешмәве турында күрсәтергә;

4) тикшерү үткәргәндә юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокукларын бозуга китергән дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

5) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Россия Федерациясе субъектында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

8.2. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир кишәрлекләрен арендалаучылар бурычлы:

1) муниципаль контроль буенча чаралар уздырганда үзләренең яисә вәкаләтле вәкилләренең булуын тәэмин итәргә;

2) җир кишәрлекләренә хокуклар турында документларны, җирләрдән файдалану

һәм саклау мәсьәләләрен җайга салучы проект-техник һәм башка материалларны тапшырырга.

8.3. Хокук бозуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез рәвештә каршылык күрсәтә торган, тикшерүләр уздырудан читләшүче һәм (яисә) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарының, муниципаль контроль органнарының мәҗбүри таләпләрне яисә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазифаи затлар яисә юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, индивидуаль эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре, физик затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

## 9. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затларның хокуклары һәм бурычлары

9.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча бурычларын үтәү өчен муниципаль контрольне үз компетенциясе чикләрендә гамәлгә ашыручы урындагы зат түбәндәгеләргә хокуклы:

Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге административ регламентта билгеләнгән тәртиптә хезмәт таныклыгын күрсәтеп контроль объектларына барырга һәм тикшерергә;

тикшерүләр нәтиҗәләре буенча җир законнарының үтәлешен тикшерү актларын төзергә;

муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга комачаулаучы гамәлләрне булдырмый калуда яисә чикләүдә, шулай ук җирләрдән файдалануны бозуда гаепле гражданнарның шәхесләрен ачыклауда ярдәм итү өчен эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

Бердәм дәүләт реестрыннан физик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар турында мәгълүматны һәм мөлкәтнең торышы, аларны куллану һәм саклау турында мәгълүмат һәм материалларны, шул исәптән, муниципаль берәмлек территориясендә контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган мөлкәткә хокукларны таныклаучы документларны мөстәкыйль рәвештә соратырга һәм алырга;

ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү турында мәсьәләләрне хәл итү өчен прокуратура һәм эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне карау өчен гамәлдәге законнарны бозу турындагы материалларны контроль функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең дәүләт органнарына җибәрергә;

Федераль салым хезмәте инспекциясенә гарызнамәләр юлларга һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле теләсә нинди мәгълүматны алырга;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башкарма комитет структурасына керүче органнардан, барлык милек рәвешендәге оешмалардан үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр һәм башка документларны соратырга һәм алырга;

җир кишәрлекләренең торышы, алардан файдалану турында мәгълүматлар һәм материалларны, шул исәптән муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җиргә хокукны таныклаучы документларне бушлай алырга.

9.2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи зат тикшерү уздырганда бурычлы:

1) мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмый калу буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

2) Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын һәм муниципаль хокукый актларны, физик затларның, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3) тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе күрсәтмәсе нигезендә аны билгеләнешенә ярашлы рәвештә үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазифаларын башкарганда гына, күчмә тикшерүне хезмәт урыны таныклыкларын, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе күрсәтмәсенең күчермәсен һәм әлеге Нигезләмәдә каралган очракларда тикшерү үткәрүне килештерү турында документның күчермәсен күрсәтеп үткәрергә;

5) җитәкчегә, башка вазифаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка тикшерү барышында катнашуына һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүенә комачауламаска;

6) тикшерү үткәргәндә шунда булган җитәкчегә, башка вазифаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка тикшерү предметына кагылышлы мәгълүмат һәм документларны бирергә,;

7) җитәкчене, башка вазифаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен, физик затны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга.

9.3 Тикшерү уздырганда муниципаль контроль органының урындагы затлары хаклы түгел:

1) мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә, әгәр мондый таләпләр әлеге вазифаи затлар аның исеменнән эш иткән муниципаль контроль органы вәкаләтләренә кермәсә; ;

1.1) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук куллану мәҗбүрилеге Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документлар таләпләренең үтәлешен тикшерергә;

1.2) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) җитәкче, башка вазифаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта планлы яисә планнан тыш күчмә

тикшерү үткәрергә, 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсендәге 2 өлешендәге 2 пунктының "б" пунктчасында каралган нигез буенча мондый тикшерүне үткәрү очрагыннан гайре, шулай ук җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир кишәрлекләре арендаторларына тиешле хәбәрнамә ирештерү очракларында җир законнары таләпләренең үтәлешен тикшерергә;

3) документлар, мәгълүмат, продукция үрнәкләре, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү мохите объектларын тикшерү пробалары бирүне таләп итәргә, әгәр алар тикшерү объекты булмаса яисә тикшерү предметына карамасалар, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен алырга;

4) күрсәтелгән үрнәкләрне сайлап алу турында беркетмәләр тутырмыйча, тикшеренүләр, сынаулар, үлчәүләр үткәрү өчен продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын, билгеләнгән рәвештә һәм үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган милли стандартлар, үрнәкләрне сайлап алу кагыйдәләре, аларны тикшерү, сынаулар, үлчәүләр, техник регламентлар белән билгеләнгән яисә башка норматив техник документлар, тикшеренүләр, сынаулар, үлчәү кагыйдәләре һәм методлары белән билгеләнгән нормадан артып киткән күләмдә пробалар алырга;

5) тикшерүне уздыру нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматны, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан гайре, таратырга;

6) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларыннан артып китәргә;

7) юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга алар хисабына контроль чараларын уздыру турында күрсәтмәләр яисә тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашырырга;

8) юридик заттан, индивидуаль эшкуардан, физик заттан башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карамагында булган яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагында булган рөхсәт документларын да кертеп, документлар һәм (яисә) мәгълүмат тапшыруны таләп итәргә;

9) юридик заттан, шәхси эшкуардан документлар, мәгълүмат бирүне тикшерү үткәрелә башлаган датага кадәр таләп итәргә. Муниципаль контроль органы тикшерү үткәрү турында күрсәтмә яисә боерык кабул ителгәннән соң ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны соратырга хокуклы.

## 10. Контроль чараларын дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлек итмичә оештыру һәм үткәрү

10.1 Муниципаль контроль органының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлеге таләп ителмәгән контроль чараларына түбәндәгеләр керә (алга таба –

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлексез генә тикшерү, контроль чаралары):

1) әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеге нигезендә җир кишәрлекләре территорияләрен планлы (рейд белән ) караулар (тикшерүләр);

2) "Интернет" мәгълүмат челтәрендә һәм гаммәви мәгълүмат чараларында урнаштырылганда мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

3) дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, юридик зат һәм индивидуаль эшкуар эшчәнлеге турында мәгълүматны анализлау юлы белән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, тәкъдим итү бурычы (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларын куллану юлы белән) мондый затларга федераль закон нигезендә йөкләнгән булса;

4) федераль законнарда билгеләнгән контроль буенча чараларның башка төрләре һәм рәвешләре.

10.2. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә контрольлек итү чаралары муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан раслана торган мондый чараларны үткәрүгә биремнәр нигезендә муниципаль контроль органының вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан үз компетенциясе чикләрендә уздырыла.

10.3. Әлеге Нигезләмәнең 10.2 пунктында күрсәтелгән биремнәрнең эчтәлеге һәм аларны рәсмиләштерү һәм муниципаль контроль органының вазифаи затлары тарафыннан дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлексез контроль чаралары нәтиҗәләрен, шул исәптән планлы (рейд белән) тикшерүләр, тикшеренүләр, үлчәүләр, күзәтүләр нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан билгеләнә.

10.4. Әлеге Нигезләмәнең 10.1 пунктында күрсәтелгән контроль буенча чаралар үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу ачыкланган очракта, муниципаль контроль органының вазифаи затлары үз компетенциясе чикләрендә мондый бозуларны кисәтү буенча чаралар күрә, шулай ук муниципаль контроль органы җитәкчесенә, әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына, юридик затка, индивидуаль эшкуарга планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар кабул итү өчен ачыкланган хокук бозулар турында мәгълүмат белән дәлилләнгән язма рәвештә күрсәтмә җибәрәләр.

## 11.Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү

11.1 Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуларны булдырмау, мәҗбүри таләпләрне бозуларга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатларында, муниципаль контроль органы ел саен аның тарафыннан расланган хокук бозуларны профилактикалау программалары нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыра.

11.2. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында

муниципаль контроль органы:

1) “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтта мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яки аларның аерым өлешләре исемлеген (аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль предметы булып тора), шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстларын урнаштыруны тәэмин итә;

2) дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча җитәкче кулланма эшләү һәм бастырып чыгару юлы белән, семинарлар һәм конференцияләр уздыру, гаммәви мәгълүмат чараларында аңлату эшләренә һәм башка ысулларга нигезләнеп мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта, муниципаль контроль органы гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларны гамәлгә кертү сроклары һәм тәртибе, шулай ук мәҗбүри таләпләрне гамәлгә кертүгә һәм үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән тиешле оештыру, техник чаралар уздыру турында тәкъдимнәр, мәҗбүри таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге турында шәрехләүләүләр (аңлатмалар) әзерли һәм тарата.

11.3 Әгәр федераль законда башкача билгеләнмәгән булса, муниципаль контроль органында әзерләнә торган хокук бозулар турында яисә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән үзара бәйләнешсез гамәлгә ашырыла торган контроль чараларын гамәлгә ашыру барышында алынган мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре яисә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, гаммәви мәгълүмат чараларыннан кергән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан гайре) булган мәгълүматларның мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлегенә зыян салу, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә китергән яки күрсәтелгән нәтиҗәләргә турыдан-туры куркыныч тудыру турында расланган мәгълүматлар булмаган очракларда булуы турында мәгълүматлар булса һәм, әгәр дә дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, юридик зат, индивидуаль эшкуар тиешле таләпләрне бозган өчен элек җаваплылыкка тартылмаган булса, муниципаль контроль органы дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына, юридик затка, индивидуаль эшкуарга мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына, юридик затка, индивидуаль эшкуарга мәҗбүри таләпләрнең, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү чараларын күрергә һәм бу хакта мондый кисәтүдә билгеләнгән вакытта муниципаль җир контроле органына хәбәр итәргә тәкъдим итә.

11.4 Мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүдә тиешле мәҗбүри таләпләргә, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә, аларны күздә тоткан норматив хокукый актка күрсәтүләр, шулай ук дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының, юридик затның, индивидуаль эшкуарның нинди конкрет гамәлләре (гамәл кылмавы) әлеге таләпләрне бозуга китергәне яисә

китерә алуы турында мәгълүмат булырга тиеш.

## 12. Тикшерү уздырганда урындагы затларның җаваплылыгы

12.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының урындагы затлары тикшерү уздырганда тиешле функцияләрен, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.